СОВЕТ
БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422725, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Большой Битаман, ул. Московская, 2В

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ БИТАМАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Олы Битаман авылы, Мәскәү ур., 2В.

тел./факс 8(84365) 62-8-47, e-mail: Bbit.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**23 май 2024 е** **№ 90**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципал районы Олы Битаман авыл җирлеге Советының 2016 елның 07 декабрендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм идарә итү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында” 41 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы прокуратурасының 17.03.2024 № 02-08-01 протесты нигезендә, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 14.11.2002 № 161-ФЗ Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципал районы Олы Битаман авыл җирлеге Советының 2016 елның 07 декабрендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм идарә итү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында” 41 нче номерлы карарына ( 08.06.2018 №89 редакциясендәге) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 маддәнең 3нче абзацында “муниипаль унитар предприятиеләр” һәм и «хуҗбалык алып бару хокукында”» сүзләренн юкка чыгагрырга исключить;

1.2. 3 маддәнең 3 пукнктында «муниципаль унитар предприятиеләр (алга таба предприятиеләр) хуҗалык алып бару хокукында» сүзләрен юкка чынарырга;

1.3. 7 маддәнең 2 абзацын түбәндәгечә бәян итәргә:

«- муниципаль учреждениегә оператив идарә итү хокукында беркетелгән муниципаль милек, яки муниципаль милектә булган предприятие, тулаем алганда, милек комплексы буларак;»;

1.4. 10 маддәдә:

а) 2 нче пунктта «муниципаль унитар предприятиеләр һәм» сүзләрен юкка чыгарырга;

б) 3 пунктта «муниципаль унитар предприятиеләр һәм» сүзләрен юкка чыгарырга;

в) 4 нче пунктны юкка чыгарырга;

г) 5 нче пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

«5. Муниципаль учреждениеләрне булдыру, бетерү һәм үзгәртеп кору, аларның уставларын раслау, әлеге учреждениеләр җитәкчеләрен вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү, хуҗалык җәмгыятьләрен төзүдә катнашу турында карарлар Олы Битаман авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.»;

1.5. 11 маддәне түбәндәгечә бәян итәргә:

«11 маддә. Муниципаль милекне муниципаль учреждениегә беркетергә

1. Муниципаль милекне учреждениегә беркетү турында Карар Олы Битаман авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә һәм Олы Битаман авыл җирлеге башкарма комитеты карары һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә кабул итү-тапшыру акты рәвешендә рәсмиләштерелә.

2. Учреждениеләрнең муниципаль милеккә карата хокуклары һәм бурычлары Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә.

3. Муниципаль милек белән оператив идарә итү хокукы Олы Битаман авыл җирлеге Башкарма комитетының учреждение белән килешү буенча кабул ителгән карары буенча, шулай ук законнарда билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән милекне законлы рәвештә тартып алу очрагында туктатылырга мөмкин.

4. Учреждение закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә юкка чыгарылганда, аңа оператив идарә итү хокукында беркетелгән учреждение милке, кредиторларның таләпләрен канәгатьләндергәннән соң, муниципаль казнага тапшырыла.»;

1.6. 15 маддәнең 3 нче пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

«3. Ышаныч идарәсенә оператив идарәдәге объектлар тапшырыла алмый.»;

1.7. 18 маддәнең 1 пунктында «, шул исәптән предприятиегә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән күчемсез милек,» сүзләрен юкка чыгарырга;

1.8. 19 маддәнең 2 нче пунктын юкка чыгарырга;

1.9. 21 маддәдә:

а) 1 пунктта «предприятие яисә» сүзләрен юкка чыгарыга;

б) 2 пунктның 3 нче абзацын юкка чыгарырга;

в) 2 пунктның 4 абзацындагы “предприятиеләр һәм” сүзен юкка чыгарырга;

1.10. 22 маддәнең 2 пунктындагы «2002 елның 14 ноябрендәге № 161-ФЗ «Дәүләт һәм муниципаль унитар предпприятиеләре турында Федераль законы», сүзләрен юкка чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.Ю.Закиров